КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 сентябрь г.Казань № 928

Архив эше турындагы законнарның үтәлешен төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу механизм карарга теркәлгән Архив эше турындагы законнарның үтәлешен төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау хакында» 2017 ел, 30 сентябрь, 734 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау хакында» 2017 ел, 30 сентябрь, 734 нче карары белән расланган Архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 10 август, 673 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

4. Бу карар имза куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин